| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 31 май г.Бугульма № 8

**Бөгелмә шәһәре территориясендә җәмәгать туклануы объектларын һәм сезонлы стационар булмаган сату объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. Бөгелмә шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне расларга (Кушымта 31)
2. Бөгелмә шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукларын сату буенча аукцион оештыру һәм үткәрү нигезләмәсен расларга (Кушымта №”).
3. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга сату-алу хокукы килешүенең формасын раслау (Кушымтпа №3).
4. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының сезонлы сату-алу килешүендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокук күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында кабул итү комиссиясе акты формасын расларга (Кушымта №4).
5. Җәмәгать туклануы объектларын һәм сезонлы стационар булмаган сату объектларын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) хакын билгеләү методикасын расларга (Кушымта №5).
6. Бөгелмә шәһәре территориясендә җәмәгать туклануы объектларын һәм сезонлы стационар булмаган сату объектларын урнаштыруга аукцион үткәрү өчен комиссия составын раслау (Кушымта №6).
7. Бөгелмә шәһәре территориясендә җәмәгать туклануы объектларын һәм сезонлы стационар булмаган сату объектларын урнаштыру схемасын раслау (Кушымта №7).

8. Бөгелмә шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сату объектларын урнаштыру турында гариза Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына юллана.
9. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының сезонлы сату-алу килешүендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокук күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында кабул итү комиссиясе акты формасын раслау буенча вәкаләтле орган итеп Бөгелмә муниципаль районы шәһәр төзелеше һәм архитектура бүлеген билгеләргә.
10. Юридик бүлеккә әлеге Нигезләмәне “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына” һәм Бөгелмә муниципаль районы сайтына урнаштырырга.
11. Әлеге Нигезләмә аны рәсми бастырган көннән үз көченә керә.
12. Нигезләмәне тормышка ашыруда контрольне үз өстемә алам.

М.В. Конков